*Гиниятуллина Л.М., Гайнуллина Г.Ф. (КФУ, Казань)*

# «АНА ТЕЛЕ» ОНЛАЙН-МӘКТӘБЕ МАТЕРИАЛЛАРЫН ГАМӘЛИ ДӘРЕСЛӘРДӘ КУЛЛАНУ

**Аннотация:** Статья посвящена рассмотрению возможностей применения видеоматериалов онлайн-школы «Ана теле» в аудиторных занятиях при обучении татарскому языку иноязычных студентов. Дается краткое описание тематики предложенных на сайте материалов, перечисляются возможные виды дополнительной работы с вышеназванными видеозаписями.

**Ключевые слова:** татарский язык, онлайн-школа «Ана теле», преподавание татарского языка.

**Application materials the online-school «Ana tele» on the practical classes**

**Abstract:** The Article is devoted to consideration of the possible application videos online-school «Ana tele» in the classroom lessons when teaching the Tatar language foreign language students. A brief description of subjects proposed for the site lists the possible types of additional work with the above video.

**Key words:** Tatar language, online-school «Ana tele», the Tatar language teaching.

Хәзерге укытучының җәмгыятьтә тоткан урыны үзгәрә бара: ул – мәгълүмат бирүче генә түгел, ә укучыларның фикерләү сәләтен үстерүче, уку һәм танып-белү эшчәнлеген актив оештыручы да. Бүген чит телле студентларга татар телен өйрәтергә,

аларның татарча аралашуларына омтылабыз икән, татар телен инновацион технологияләр кулланып укыту көн тәртибендәге мөһим мәсьәләләрнең берсе булуын истә тотарга тиешбез.

Яңа технология – һәрвакыт кызыксыну чыганагы, шуңа күрә дә ул фәнне өйрәнүгә этәргеч бирә. Сүзебез инде өч елдан артык эшләп килә торган инновацион проектларның берсе – «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе [1] турында барачак.

Хәзерге вакытта белем бирү оешмаларында татар телен аралашу чарасы буларак укыту, шулай ук тел ярдәмендә студентларга рухи һәм әхлакый тәрбия бирү, аларның коммуникатив культурасын формалаштыру бурычы куела. Татар телен гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә, студенлар көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләренә ия булырга тиешләр. Татар телен дәүләт теле буларак өйрәткәндә, укытучының төп максаты – студентны иркен аралашырга, ул телдә дөрес итеп сөйләшергә, сөйләргә өйрәтү. Укытучыларга бу юнәлештә «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе материаллары ярдәмгә килә. Алга таба әлеге белем бирү сайтында урын алган видеоязмаларга тукталырбыз. Аларны татар телен чит тел буларак укытканда куллануның отышлы якларын санап чыгыйк: бердән, интерактивлык; икенчедән, аутентлык; өченчедән, телне этномәдәни тирәлектә өйрәнү мөмкинлеге һ.б. «АНА ТЕЛЕ» сайтында урнаштырылган видеоматериаллар студентка ситуацияне табигый мохиттә күреп, ишетеп аңларга, мәгълүматны дөрес кабул итәргә ярдәм итә.

Сайтта лексик, грамматик материал 9 дәрәҗәдә тәкъдим ителә. Аларның һәрберсе, үз чиратында, 8 бүлеккә бүленгән. Әлеге бүлекләр эчендә 4 дәрес урын алган. Шул дүрт дәреснең һәрберсе видеоязмадан башланып китә. Димәк, төрле лексик берәмлекне, грамматик категорияләрне өйрәнү өчен әлеге онлайн-мәктәп сайтына 288 видеоязма урнаштырылган. Фильмны караганда, студент тәкъдим ителгән биремнәрне дә үти бара. Бу бер урынга тупланган бай материал татар теле дәресләрендә файдалану өчен әзер әсбап.

«АНА ТЕЛЕ»ндәге һәр фильм аерым бер лексик теманы үз эченә ала дидек. Мәсәлән, «Туган көн», «Танышу», «Бәйрәмнәр», «Кечке аш», «Сәламәтлек», «Һава торышы», «Аралашу кагыйдәләре», «Мәдәният дөньясында», «Сәяхәт итәбез», «Татар дөньясы», «Музыка турында сөйләшү» һ.б.

Кыскача гына һәр дәрәҗәдә

чагылыш тапкан лексик тамаларга тукталыйк.

Беренче дәрәҗә үз эченә танышу, үзең белән таныштыру, гаилә турында сөйләшү кебек темаларны берләштерә.

Икенче дәрәҗәдә атна көннәре, көндәлек режим, туган көн, һава торышы, ел фасыллары турында сүз алып барыла.

Өченче дәрәҗә милләт һәм телләр өйрәнү, йорт-җир, шәһәрдә юнәлешне күрсәтү кебек темаларны берләштерә.

Дүртенче дәрәҗә эш көне, эш эзләү, спорт белән шөгыльләнү, спорт төрләре турында сөйләшүгә багышлана.

Бишенче дәрәҗәдә бәйрәмнәр, ял итү, йорт хайваннары, урман җәнлекләре, дуслар белән аралашу, табипка бару кебек темалар карала.

Алтынчы дәрәҗә кино, сәяхәт, яңа очрашулар, яхшы һәм начар гадәтләр кебек темаларны яктырта.

Җиденче дәрәҗәдә аралашу кагыйдәләре, табигатьне саклау, массакүләм информация чаралары, Татарстан һәм Рәсәй шәһәрләре, спорт ярышлары хакында сөйләшергә тәкъдим ителә.

Сигезенче дәрәҗәдә бүлмә гөлләре, сәламәтлек, медицина, музыка, теләкләр һәм хыял, хисләр, туганлык мөнәсәбәтләре кебек темалар күтәрелә.

Тугызынчы дәрәҗәдә татар дөньясы, халыкара мөнәсәбәтләр, югары белем системасы, Татапстанның табигате, мәдәнияты хакында сүз алып барыла.

Югарыда әйткәннәрдән күренгәнчә, кайсы гына белгечлек буенча белем алган студентлар белән эшләсә дә, укытучы үзенә кирәкле материалны таба ала. Шул рәвешле, әлеге кыскача анализ «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбендәге видеоязмаларны татар теленнән гамәли дәресләрдә куллануның отышлы булуны тагын бер кат дәлилли.

Видематериал – җиңелдән катлаулыга принцибын саклап, төрле лексик темаларны эченә алып төзелгән дәрәҗәнең бер өлеше дидек. Аларда, лексикадан тыш, морфологик һәм синтаксик категорияләр, стиль нормалары, этномәдәни үзенчәлекләр урын алган. Димәк, татар теленә өйрәткәндә, фильмнарны куллану студентларның язма сөйләмен камилләштерү өчен дә отышлы.

Билгеле бер лексик теманы үз эченә алган фильмнарны карап, тыңлап, биремнәрне үтәгәннән соң, укытучы үз фантазиясен эшкә җигеп, төрле язма эшләр тәкъдим итә ала. Шундыйлардан берничәсен мисал итеп китерәбез.

1. Тыңлаган диалогны монолог итеп үзгәртеп язу.

2. Тыңлаган текст буенча

сорау төзеп язу.

3. Сыйныфташларының сорауларына җавап бирү.

4. Вакыйганың кайда (кайчан, нинди обстановкада, кемнәр катнашында) баруын язмача тасвирлау.

5. Охшаш ситуация буенча диалог төзеп язу.

Шулай ук тыңланган диалогка карата төрле язма биремнәр тәкъдим итәргә мөмкин. Укытучы, дәрескә диалог репликаларының язма вариантын алдан әзерләп, әлеге репликалардан диалог төзеп язарга тәкъдим итә ала. Өйрәнелә торган грамматик темага бәйләп тә эш бирергә мөмкин. Мәсәлән, «Шәһәрдә юнәлешне күрсәтү» темасына бирелгән фильмны алыйк. Бу видиоязманы бәйлекләр һәм бәйлек сүзләрне өйрәнгәндә, кабатлаганда карарга мөмкин. Видеофайлны карагач, җөмләләрне бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән тулыландырып язуны башкарып була.

Бүгенге инновацион технологияләр чорында татар теле укытучылары да эшчәнлекләрен заман таләпләренә туры китереп, булган мөмкинлекләрдән, әзер проектлардан, чаралардан нәтиҗәле һәм макстка ярашлы файдаланса иде дигән теләктә калабыз.

Әдәбият һәм чыганаклар:


1. «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе. [Электронный ресурс]. – Режим доступа: anatele.ef.com.

2. Айдарова С.Х., Гиниятуллина Л.М. Обучение студентов методическим принципам развития речи / С.Х.Айдарова, Л.М.Гиниятуллина //Модернизация педагогического образования: сборник научных трудов Международного форума. – К., 2015. – С.17-20.